ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.05.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1269**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 17 апрелендәге «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1731 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 04 декабрендәге 4547 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) күрсәтелгән карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый (http://pravo.tatarstan.ru) мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма
комитетының
2025 елның 13 маендагы
1269 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 23 320 |
| 2 | 1,0114 | 23 586 |
| 3 | 1,0233 | 23 863 |
| 4 | 1,0346 | 24 127 |
| 5 | 1,0473 | 24 423 |
| 6 | 1,0595 | 24 707 |
| 7 | 1,0728 | 25 017 |
| 8 | 1,0855 | 25 314 |
| 9 | 1,0983 | 25 612 |
| 10 | 1,1119 | 25 929 |
| 11 | 1,1251 | 26 237 |
| 12 | 1,1393 | 26 568 |
| 13 | 1,1535 | 26 899 |
| 14 | 1,1675 | 27 226 |
| 15 | 1,1823 | 27 573 |
| 16 | 1,1973 | 27921 |
| 17 | 1,2124 | 28 273 |
| 18 | 1,2280 | 28 637 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә